**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 февраль № 119

г. Казань

«Кукмара муниципаль районындагы Балалар һәм үсмерләр өчен «Солнышко» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен бетерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 422110, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, шәһәр тибындагы Кукмара поселогы, Рабочий переулок урамы, 7 нче йорт адресы буенча урнашкан «Кукмара муниципаль районындагы Балалар һәм үсмерләр өчен «Солнышко» социаль приюты» дәүләт казна учреждениесен (алга таба – «Солнышко» социаль приюты) бетерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

ундүрт көн эчендә:

«Солнышко» социаль приютын бетерү комиссиясе составын расларга;

«Солнышко» социаль приютын бетерү тәртибен һәм вакытларын Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә билгеләргә;

«Солнышко» социаль приютын бетерү турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә «Солнышко» социаль приютының бетерелү процессында булуы турындагы мәгълүматларны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү өчен теркәүче органга тапшырырга;

бетерелә торган учреждениегә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтеннән, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле мөлкәттән алга таба файдалану турында утыз көн эчендә Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына тәкъдимнәр кертергә;

учреждение бетерелү аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы

нигезендә тәэмин итәргә, шулай ук «Солнышко» социаль приютын бетерү буенча законнарда күздә тотылган башка чараларны гамәлгә ашырырга.

3. «Солнышко» социаль приюты йөкләмәләре, шул исәптән суд карарларын үтәү нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тора дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдим иткән исемлек нигезендә «Солнышко» социаль приютына элек беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен законнарда билгеләнгән тәртиптә ике ай вакыт эчендә бирүне тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына бу карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук аларны бетергәндә 2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә һәм «2015 елга һәм 2016 һәм 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\119.docx